ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
САРСАК-ОМГИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
САРСАК-УМГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31.03.2020 Сарсак-Умга авылы № 8

2020 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 174 статьясы, «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләр турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 22 июнендәге 796 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Сарсак-Умга авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кушымтада бирелгән 2020 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлегенең салым чыгымнарын бәяләүне уздыру тәртибен һәм салым чыгымнары исемлеген булдыру тәртибен расларга.

2. Әгерҗе районында Россия Федерациясе Салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча 9 нчы районара инспекциясенә 2020 елның 1 сентябренә кадәр Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлеге башкарма комитетына хисап елында һәм хисап елыннан алдагы елда белешмәләр җибәрергә тәкъдим итәргә:

ташламалардан файдаланучы түләүчеләр саны турында;

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлеге бюджетының Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлегенең һәр салым чыгымы буенча бирелгән керемнәре суммалары турында.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкче Т.С. Николаева

Расланган
Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Сарсак-Умга авыл җирлеге
башкарма комитетының
31.03.2020 № 8 карары белән

# 2020 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлегенең салым чыгымнарын бәяләүне уздыру һәм бирелгән салым чыгымнары исемлеген булдыру тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлегенең салым чыгымнарын бәяләү (алга таба - Тәртип, муниципаль берәмлек) кагыйдәләрен билгели.

2. Әлеге Тәртиптә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләр турында» 2019 елның 22 июнендәге 796 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләр (алга таба - гомуми таләпләр) белән билгеләнгән терминнар һәм төшенчәләр кулланыла.

3. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын муниципаль программаларга кертү муниципаль программалар максатларыннан, муниципаль программаларның структур элементларыннан һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый сәясәте максатларыннан чыгып гамәлгә ашырыла.

4. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләү максатларында муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты:

муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары исемлеген төзи;

муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләү нәтиҗәләрен анализлауны һәм гомумиләштерүне гамәлгә ашыра.

## II. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары исемлеген төзү

5. Чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары Исемлеге муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты тарафыннан төзелә һәм агымдагы елның 1 июненә кадәр раслана.

6. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының расланган Исемлеге муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында агымдагы елның 1 июленнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

7. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләү максатларында Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча 9 нчы районара инспекциясе Әгерҗе районында муниципаль берәмлекнең башкарма